





# Тамчы

«2 нче санлы Җәлил урта мәктәбе» газетасы

апрель №9 (69) 2016-2017 нче уку елы



# “Тукай айлыгы” - икенче атна

**10 нчы апрель.**

Мәктәбебездә “Тукай айлыгы” дәвам итә. Аның икенче атнасы татар халкының рухи мирасына багышланды. Без аны “Халкыбызның күңел җәүһәрләре атналыгы” дип атадык. Бу атна да төрле чараларга бай булды. Атна 7 нче сыйныфлар арасындагы “Әдәби КВН”нан башланды. 3 команда татар халык авыз иҗаты әсәрләрен белүдә ярыштылар.Чараны Нуртдинова Г.С. оештырды.

**11 нче апрель.**

Традицион “Зирәк тиен” бәйгесе. Бу уку елында анда 91 укучы үзенең көчен сынап карады. Нәтиҗәләр май башында билгеле булачак.

**11 нче апрель.**

Бу көнне мәктәпкә гармунчылар да килде. “Уйнагыз, гармуннар” чарасында гармун уйнарга үзлегеннән өйрәнгән Әлфия апа Сәгыйтова белән Яхъя абый Замаев осталык дәресләре күрсәттеләр. Бер дәрес кысаларына гына сыешып булмады, шуңа да бу чара мәктәбебезнең чыгарылыш сыйныф укучылары белән халкыбызның югалып бара торган гореф-гадәтләре турында ачыктан-ачык сөйләшүгә күчте. Гомерләрен нефтьче хезмәтенә багышлаган, ләкин әдәбияттан, музыкадан аерылмаган өлкәннәр - үз фикерләрен, яшьләр үзләренекен белдерде. Кайдадыр бәхәсләштек, кайдадыр борчулар уртак булды. Чарада бистә шагыйре Әнвәр Төхватуллинның катнашуы ямь өстенә ямь булды. Ә 9 А сыйныфы укучысы Булат Сөләйманов осталар алдында сынау тотты. Аның баянда уйнавын өлкәннәр югары бәяләделәр. Чараны Шәйдуллина Л.К. оештырды һәм алып барды.

**12 нче апрель.**

Шушы көнне Җәлил мәдәният йортында Әлмәт драма театры “Кар астында кайнар чишмә” спектаклен күрсәтте. Ул - якташыбыз Аяз Гыйләҗев әсәре. Баш рольне дә якташыбыз Эдуард Латыйпов башкарды. Искиткеч матур, уйландыра торган тамаша булды бу. Театр коллективына зур рәхмәт.

**12 нче апрель.**

Бу - Халык ашлары көне. Ул татар халык ашлары күргәзмәсеннән башланып китте һәм көне буена сузылган осталык дәресләре белән дәвам итте. Башта укучылар Гәмбәрия Рәис кызы Вәлиевадан чәкчәк пешерергә өйрәнделәр. Аннан Фирая Ислам кызы Зиннәтуллина аларны гөбәдия пешерү серләренә өйрәтте. Мәктәбебез укытучылары Ләйсән Әнвәр кызы Галиева – кыстыбый, Энже Илсур кызы Вәлиева коймак пешерү осталыклары белән уртаклаштылар.

**15 нче апрель.**

Атнаның соңгы көнендәге осталык дәресе үзенә шамаил ясаргә өйрәнергә теләүчеләрне җыйды. Аны “Җәлилнефть” нефть һәм газ чыгару идарәсе” хезмәткәре Асия Кәшиф кызы Каюмова алып барды.

**14 нче апрель**

8 А сыйныфы кызлары Гарифуллина Сөмбел һәм Фазилова Камилла (җитәкчеләре Шәйдуллина Ч.К.) россиякүләм үткәрелгән “Тарих эзләреннән” бәйгесенең бүләкләү тантанасында катнаштылар. Ул Казанның Милли музеенда булды

.

**«Халкыбызның күңел җәүһәрләре” атналыгыннан фоторепортаж**












**“Нәсел шәҗәрәләре” конкурс-күргәзмәсе нәтиҗәләре:**

- 1 нче урын - Хабибуллина Альбина (9 Б сыйныфы), Каримов Илназ, Реназ (2 В сыйныфы)
- 2 нче урын – Идрисова Диана (6 А сыйныфы), Хакимов Ранис (2 В сыйныфы)
- 3 нче урын – Вадиков Раил (6 В сыйныфы), Мусина Динара (7 Б сыйныфы), Раянова Диләрә (7 б сыйныфы), Миннегалиев Раниль (2 В сыйныфы)

**К О Т Л Ы Й Б Ы З !**

**Шеф редактор**: Шайдуллина Ландыш Камил кызы

Редколлегиядә: Зәкиева Азалия, Мөхәмәтгалиева Гүзәл, Насыйбуллин Данияр (6-в)